МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_____________ №_____________

г.Казань

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алулары Тәртибен раслау турында

2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» №79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 10 октябрендәге «Россия Федерациясендә аерым дәүләт вазыйфаларында, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларында булучыларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр, һәм башка төр аерымлык билгеләре алулары тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында" 506 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 гыйнварындагы "Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган дәүләт вазыйфаларында булучы затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр һәм башка төр аерымлык билгеләре алулары тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында" УП-5 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алуларының әлеге Тәртибен (алга таба-Тәртип) расларга.
2. Кадрлар бүлеге башлыгына Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында һәм гражданнар белән хезмәт килешүләре төзегәндә аларны әлеге боерык белән таныштыруны тәэмин итәргә;

3. Җыелма булегенә әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Хөкүмәте Рәсми порталының Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы сайтының “Дәүләт бүләкләре” бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары –
министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы
сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының
2016 елның 05 апрелендәге
67-ОД номерлы боерыгы
белән расланган

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алулары
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык), әгәр дә әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына кирә икән, чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан бүләкләр, мактаулы һәм махсус исемнәр (фәнни- исемнәрдән тыш) (алга таба – исемнәр, бүләкләр) алу тәртибен регламентлый.

2. Исем, бүләк алганда гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары - министрыннан (алга таба - Министр) рөхсәт алырга тиеш.

3. Чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый берләшмәдән һәм дини оешмадан исем, бүләк алган яки алачаклыгы турында искәртелгән гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар бүлегенә чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый берләшмәдән һәм дини оешмадан исем, бүләк алуга рөхсәт бирү турында әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендәге формада төзелгән үтенеч (алга таба –үтенеч) тапшыра.

Үтенечне карау вакыты үтеенч әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә кадрлар бүлегендә теркәлгән көннән соңгы 10 эш көнен тәшкил итә.

4. Исемнән, бүләктән баш тартучы гражданлык хезмәткәре өч эш көне дәвамында кадрлар бүлегенә чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә һәм дини еошмадан мактаулы һәм махсус исем, бүләк алудан баш тарту турында әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге формада төзелгән белдерү кәгазен (алга таба- белдерү кәгазе) тапшыра.

5. Исемне, бүләкне Министр үтенечне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәнче алган гражданлык хезмәткәре исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә документларның төп нөсхәләрен аларны алганнан соңгы өч эш көне дәвамында Министрлыкның кадрлар бүлеге башлыгына җаваплы саклanышка

тапшыра. Бу вакытта әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге формада кабул итү-тапшыру акты төзелә.

6. Гражданлык хезмәткәре эш командировкасына исем, бүләк алса яки аларны алудан баш тартса, үтенеч яки белдерү кәгазен тапшыру вакыты гражданлык хезмәткәренең эш командировкасыннан кайткан көненнән башлап исәпләнә.

7. Гражданлык хезмәткәре аннан тормаган сәбәпләр аркасында үтенеч яки белдерү кәгазен, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә документларның төп нөсхәләрен әлеге Тәртипнең 3-5 пунктларында билгеләнгән вакытлар эчендә тапшыра алмаганда ул үтенеч яки белдерү кәгазен, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә документларның төп нөсхәләрен мондый сәбәп беткәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенечне (белдерү кәгазен) әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендәге формада төзелгән үтенечләрне (белдерү кәгазъләрен) теркәү журналына теркәү аның керү көнендә кадрлар бүлеге тарафыннан башкарыла. Теркәлгән үтенечне (белдерү кәгазен) кадрлар бүлеге карау өчен ике эш көне эчендә Министрга юллый.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә министрның үтенечне карау барышында кабул ителгән карары турында хәбәр итә һәм аңа, имза куйдырып, үтенечнең министр резолюциясе салынган, кадрлар бүлеге печате белән расланган күчермәсен тапшыра. Үтенечнең (белдерү кәгазенең) министр резолюциясе салынган төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси делосына теркәлә.

10. Гражданлык хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенече Министр тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта Министрлыкның кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Бу вакытта әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге формада кабул итү – тапшыру акты төзелә.

11. Министрның гражданлык хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенечен канәгатьләндерүдән баш тартуы очрагында кадрлар бүлеге 10 эш көне эчендә исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини оешманың тиешле органына юллый.

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алулары Тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары-
Татарстан Республикасы сәнәгать
һәм сәүдә министрына

______________________________

______________________________
(Ф.И.Ә., вазыйфасының аталышы)

Чит дәүләт, халыкара оешма,
сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә һәм дини оешмадан
мактаулы һәм махсус исем, бүләк алуга ризалык бирү турында
Үтенеч

Миңа ______________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләк аталышы)

______________________________________________

______________________________________________
(нинди хезмәтләре өчен һәм кем тарафыннан бирелә, нинди хезмәтләре өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

______________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар тапшыру вакыты һәм урыны)

алуга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Мактаулы яки махсус исем алуга документлар, бүләк һәм аңа документлар ней, (кирәклесенең астына сызарга) ______________

______________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләкнең аталышы)

______________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләккә документлар исеме)

______________________________________________

20__елның "__" ________ номерлы тапшыру – кабул итү акты буенча Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының кадрлар бүлегенә тапшырылды.

"__" ________ 20__ ел ____________________ ______________________________
(имза) (имзаның тулысынча язылышы)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алулары Тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары-
Татарстан Республикасы сәнәгать
һәм сәүдә министрына

____________________________________

____________________________________
(Ф.И.Ә., вазыйфасының атальшы)

## Чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә һәм дини оешмадан мактаулы һәм махсус исем, бүләк алудан баш тарту турында Белдерү

Минем тарафтан________________________________________________________

____________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләкнең атальшы)

____________________________________________________________________
(нинди хезмәтләре өчен һәм кем тарафыннан бирелә, нинди хезмәтләре өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнә)

"__" ________ 20__ ел ________________ ________________________________
(имза) (имзаның тулы язылышы)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алулары Тәртибенә 3 нче кушымта

Тапшыру-кабул итү акты

«___» ____________ 20___ ел №_________

Без, түбәндә имза куючылар, ________________________________________________ (Ф.И.Ә., вазыйфасы) тапшыруы/кабул итүе (кирәклесенең астына сызарга), ә Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының кадрлар бүлеге__________________ (Ф.И.Ә.) түбәндәгеләрне кабул итүе/тапшыруы (кирәклесенең астына сызарга) турында акт төзедек:

| № п/п | Аталышы | Саны (данә) | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды
____________________________
(имза) (имзаның тулы язылышы)

Кабул итте
____________________________
(имза) (имзаның тулы язылышы)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр алулары Тәртибенә 4 нче кушымта

Үтенечләрнең (белдерү кәгазьләренең) исәбен алып бару

# ЖУРНАЛЫ

| № | Үтенечне (белдерү кәгазен) тапшыручы гражданлык хезмәткәренең Ф.И.Ә.и. | Үтенечне (белдерү кәгазен) тапшыручы гражданлык хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенеч (белдерү кәгазе) керү көне | Бүләкнең, исемнең аталышы | Кабул итү-тапшыру акты реквизит-лары (булса) | Үтенечне (белдерү кәгазен) кабул итүче затның имзасы, Ф.И.Ә.и. | Үтенечне (белдерү кәгазен) тапшыручы затның имзасы, Ф.И.Ә.и. | Министр карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |